| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.05.2022 г.Лениногорск № 474

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 30 ноябрендәге 1274 номерлы карары белән расланган Бинаны торак урын дип, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 6 апрелендәге «Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 608 номерлы карарына таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 30 ноябрендәге 1274 номерлы карары белән расланган Бинаны торак урын дип, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Күпфатирлы йорт дип Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясының 6 өлешендә билгеләнгән билгеләргә туры килә торган бина танылa.;

12 пунктның 1 абзацында «яраклылык турында (яраксызлык)» сүзләреннән соң «торак» сүзен өстәргә;

14 пунктны дүртенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләрнең булмавы турында;».

2.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорскские вести» газетасында бастырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет - сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) гражданнар күзәтү өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Руководитель З.Г. Михайлова

Л.М.Галимова
5-44-72